СОВЕТ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23.09.2021 п.г.т. Аксубаево № 75

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының 2014 елның 11 апрелендәге 202 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия булган гражданнар исемлекләрен әзерләү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында «Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 22 декабрендәге 114-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының 2014 елның 11 апрелендәге 202 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә түләүсез җир кишәрлекләре алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибенә (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының 2017 елның 16 мартындагы 95 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 18 пунктта «дача төзелеше,» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 17 пунктта «дача төзелеше,» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 3 пунктта «дача төзелеше,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Аксубай

муниципаль районы сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,

Совет Рәисе К. К. Гыйлманов